СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.12.2021 г. Заинск № 190

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 87-89 статьяларына нигезләнеп, Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Советының 2014 елның 24 июнендәге 385 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына кертелгән үзгәрешләрне билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынганнан соң бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар, үз көченә керүнең башка вакыты билгеләнгән пунктлардан тыш, дәүләт теркәве һәм билгеләнгән тәртиптә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарга кушымтаның 1.1 пунктның «б» пунктчасы һәм 1 өлешнең 1.2 пунктының «в» пунктчасы, 5 пунктның «в» пунктчасы, 6 пунктның «г» пунктчасы, 8 пункт 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы

Советының законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Зәй муниципаль районы Советының 2021 елның 27 декабрендәге 190 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставында үзгәрешләр**

Зәй муниципаль районы Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 6 статьяда:

1.1. 1 өлештә:

а) 5 пунктта «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләре белән алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктны өстәргә:

«9.1) шәһәр һәм авыл җирлекләре чикләре белән чиктәш муниципаль районнар чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;»;

в) 27 пунктта «файдалану һәм саклау» сүзләрен «саклау һәм файдалану» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 3 өлештә:

а) түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктны өстәргә:

«1.1) җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

б) 2 пунктта «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләре белән алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 12.1 һәм 12.2 пунктларын өстәргә:

«12.1) авыл җирлегенең торак пунктлары җирләрендә урнашкан участок урманчылыкларын төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү, шулай ук авыл җирлегенең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләү һәм раслау турында карарлар кабул итү;

12.2) авыл җирлеге торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман корылышы чараларын гамәлгә ашыру;»;

б) 16 пунктта «файдалану һәм саклау» сүзләрен «саклау һәм файдалану» сүзләренә алмаштырырга.

2. 19 статьяның 12 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш

кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияләрне ызанлау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карарлар проектлары, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында карарлар проектлары буенча, расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану рөхсәт ителгән бер төрне башка төргә үзгәртү мәсьәләләре буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар яисә иҗтимагый фикер алышулар үткәрелә.»;

3. Пункт 7 части 7 статьи 28 изложить в следующей редакции:

«7) Россия Федерациясе гражданлыгы, яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, чит ил гражданлыгы (подданство) булу яисә яшәүгә рөхсәт төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукынраслый торган башка документы яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданы документы булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;»;

4. Пункт 9 части 1 статьи 41 изложить в следующей редакции:

«9) Россия Федерациясе гражданлыгы, яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, чит ил гражданлыгы (подданство) булу яисә яшәүгә рөхсәт төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданы документы булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;»;

5. 45 статьяда:

а) 3 пунктта җиденче абзацта «файдалану һәм саклау» сүзләрен «саклау һәм файдалану» сүзләренә алмаштырырга.

б) 4 пунктта «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләре белән алмаштырырга;

в) 7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-шәһәр һәм авыл җирлекләре чикләре белән чиктәш муниципаль районнар чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итә;»;

6. 45.1 статьяда:

а) дүртенче абзацта «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының

сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләре белән алмаштырырга;

б) унтугызынчы абзацта «файдалану һәм саклау» сүзләрен «саклау һәм файдалану» сүзләренә алмаштырырга.

в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;»;

г) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«-авыл җирлегенең торак пунктлары җирләрендә урнашкан участок урманчылыкларын төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү, шулай ук авыл җирлегенең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләү һәм раслау турында карарлар кабул итә;

-авыл җирлеге торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман корылышы чараларын гамәлгә ашыра;»;

7. 50 статьяның 1 өлеше 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе гражданлыгы, яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, чит ил гражданлыгы (подданство) булу яисә яшәүгә рөхсәт төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданы документы булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;»;

8. 80 статьяның 7 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документлар.».